Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре
“Катнаш төрдәге 3нче “Айсылу” балалар бакчасы

**Педагогик киңәшмәдә**
**кабул ителде**

Беркетмә № 1
“ 31 ” 08. 2021

**Раслады:**
МББМБУ РТ Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре “Катнаш төрдәге
3нче“Айсылу” балалар бакчасы мөдире
вазыйфаларын башкаручы
_________ Р.Х. Исламова
“ 31 ” 08 2021

# Уртанчылар төркеме өчен эш программасы

Тәрбиячеләр: Зарипова С.Н.

Валиуллина Л.Р.

2021-2022 нче уку елы

**Эчтәлек**

Аңлатма язуы.....................................................................................................................................3

Уртанчылар төркемендә көндәлек режим…………………………………...........................................4

Белем бирү эшчәнлеге.........................................................................................................................5

Балалар психик үсешнең яшь үзенчәлекләре.......................................................................................6

Тәрбия һәм белем бирү бурычлары.................................................................................................... 7

Танып белү “Танып белү”(иң гади матиматик күзаллауларын булдыру) белем бирү өлкәсе.........................................................................................................................................................10

Танып белү. Әйләнә – тирә белән таныштыру.....................................................................................19

Конструкцияләү /Төзү/.........................................................................................................................25

“Аралашу” белем бирү өлкәсе. Сөйләм үстерү.......................................................................................27

Матур әдәбият уку................................................................................................................................32

Иҗади сәнгать эшчәнлеге. Рәсем буенча перспектив план......................................................................35

Әвәләү буенча перспектив план............................................................................................................40

Кисеп-ябыштыру буепча перспектив план...............................................................................................43

Юл йөрү кагыйдәләренә аңлатма язуы. Юл йөрү кагыйдәләре буенча перспектив план..........................................................................................................................................................46

Милли төбәк компоненты.......................................................................................................................47

Ата-аналар белән эш планы..................................................................................................................49

Мониторнинг..........................................................................................................................................54

**Аңлатма язуы**

Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре “Катнаш төрдәге 3нче “Айсылу” балалар бакчасының мәктәпкә әзерлек төркеме эш программасы **Туганнан алып мәктәпкә кадәр.** Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы / Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева. – М.: МОЗАИКА-СИНТЕЗ, 2012./; **Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы** (Р.К. Шаехова. – РИЦ, 2012.) на нигезләнеп төзелде.

Программаның төп бурычлары- мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып, физик һәм психик сыйфатларны төрле яклап үстерү, баланы хәзерге җәмгыятьтә яшәргә әзерләү булып тора.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренчел әһәмияткә ия:

- Һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;
- Балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- Балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- Тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- Балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- Гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә учреждение тормышында катнашуын тәэмин итү;
- Балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- Региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

Программада Федераль дәүләт таләпләре буенча белем бирү өлкәләре каралган. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомум ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Гуманлылык принцибын исәпкә алып, белем бирү процессы бала шәхесен ихтирам итүгә һәм психологик яклanганлык хисләре булдыруга юнәлдерелә.

Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирел

**Уртанчылар төркемендә** 20 бала йөри.

**Көндәлек режим**

**Көндәлек режим –** балаларның эшчәнлек төрләре һәм ялының рациональ дәвамлылыгы, дөрес чиратлашуы.

| **Режим вакыты** | **Сәгате** |
|---|---|
| Балаларны кабул итү, тикшерү, һавада булу, уеннар, дежур тору | 6.00-8.00 |
| Иртәнге гимнастика | 7.55-8.00 |
| Ирекле уеннар, дежур тору | 8.05-8.25 |
| Иртәнге ашка әзерлек, ашау вакыты | 8.25-8.45 |
| Уеннар, турыдан – туры белем бирү эшчәнлегенә әзерлек | 8.45-9.00 |
| Турыдан – туры белем бирү эшчәнлеге | 9.00-9.20<br>9.30 -9.50 |
| Уеннар, урамга чыгарга әзерлек, һавада булу | 9.50-11.30 |
| Урамнан керү, көндезге ашка әзерлек, ашау вакыты | 11.30-12.00<br>12.00-12.30 |
| Көндезге йокыга әзерләнү, көндезге йокы | 12.30-15.00 |
| Йокыдан уяту, һава – су процедуралары | 15.00-15.05 |
| Төшке аш | 15.05 – 15.15 |
| Уеннар, мөстәкыйлж эшчәнлек, индивидуаль эш, турыдан – туры белем бирү эшчәнлеге, хезмәт | 15.15-16.15 |
| Кичке ашка әзерлек, ашау вакыты | 16.15-16.35 |
| Түгәрәк эшләре, саф һавага чыгу, балаларны өйләренә озату | 16.35-18.00 |

**2021-2022 уку елына оештырылган белем бирү эшчәнлеге**

| | | |
|---|---|---|
| Дүшәмбе | 9.00 – 9.20 | Физик үсеш /Физкультура/ |
| | 9.30 - 9.50 | Нәфис – нәфасәти үсеш /Рәсем/ |
| Сишәмбе | 9.00 - 9.20 | Танып белү /Иң гади матем.күзаллаулар формалаштыру/ |
| | 9.30 – 9.50 | Нәфис – нәфасәти үсеш /Музыка/ |
| Чәршәмбе | 9.00 – 9.20 | Танып белү/ Әйләнә – тирә белән таныштыру |
| | 9.30 – 9.50 | Физик үсеш /Физкультура/ |
| Пәнҗешәмбе | 9.00 – 9.20 | Нәфис – нәфасәти үсеш /Музыка/ |
| | 9.30 – 9.50 | Физик үсеш /Физкультура/ |
| Җомга | 9.00 - 9.20 | Нәфис – нәфасәти үсеш /Әвәләү/Кисеп-ябыштыру/ |
| | 9.30 – 9.50 | Сөйләм үсеше /Сөйләм үстерү/Матур әдәбият уку/ |

Барлыгы 10 шөгыль, 20 минут

Режим моментында: дүшәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе – рус теле. Сишәмбе – төзү.

**Балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре**

Уртанчы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә рольле мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Бу яшьтәге балалар кабул ителгән рольдән үзләрен аера башлыйлар. Уен процесында рольләр үзгәрергә мөмкин. Алар үзләре өчен түгел, ә уенны мәгънәле итү өчен уйный башлыйлар. Уендагы һәм чынбарлыктагы мөнәсәбәтләр аерымлана.

Сүрәтләү эшчәнлеге шактый үсеш ала. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән форма ала. Кешенең график сүрәте гәүдә, күз, авыз, борын, чәч, кайвакыт кием һәм аның детальләре булу белән характерлана. Сүрәтләү эшчәнлегенең техник ягы камильләшә. Балалар төп геометрик фигураларны ясый, кайчы белән кисә, сүрәтләрне кәгазгә ябештерә алалар һ.б.

Конструкцияләү катлаулана. 5-6 детальдән торган корылмалар барлыкка килә. Уйлап чыгарып конструкцияләү, шулай ук төзү эзлеклелеген планлаштыру күнекмәләре формалаша.

Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың унай үзгәрешләре белән характерлана. Җитезлек, хәрәкәт координациясе үсә. Кечкенәләр белән чагыштырганда балалар бу яшьтә тигезлекне яхшы саклыйлар, зур булмаган тоткарлыкларны атлап чыгалар. Туп белән күнегүләр катлаулана.

Зиһенгә алу сәләте күберәк үсеш ала. Балалар бу яки теге предметка охшаган форманы атый беләләр. Алар катлаулы объетларда гади формаларны аерып күрсәтә һәм гади формадан катлаулы объектлар барлыкка китерә алалар. Балалар предмет төркемнәрнең сенсорик билгеләре – зурлыгы, төсе буенча тәртипкә салырга, биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле. Хәтер күләме үсә. Балалар 7-8 предметның исемен истә калдыра алалар. Истә калдыру мөмкинлекләре үсә. Алар олылар тапшырган эшне истә калдырылар, кечкенә шигырьләрне ятлый алалар һ.б.

Тасвирлый.фикерләү, сәләте үсә башлый. Балалар катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишүдә гади схемалаштырылган сүрәтләр кулланалар. Алар схема буенча төзи, лабиринтлы мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күрә белү сәләте үсә. Объектларның пространствада урнашулары нигезендә, балалар аларнын узара йогынты ясашуы нәтиҗәсендә нәрсә килеп чыгасын әйтә алалар. Тик аларга читтән күзәтүе позициясенә басу һәм образларны күзаллап үзгәртү әлегә авыр.

Күз алдына китерү, уйлап чыгару сәләте үсә. Оригинальлек һәм ирекле булу кебек сыйфатлар формалаша. Балалар мөстәкыйль рәвештә бирелгән темага зүр булмаган әкият уйлап чыгара алалар.

Игътибарлылык сәләте үсә. Бала 15-20 минут дәвамында игътибарын туплап эшли алырга сәләтле. Ул нинди дә булса эш эшләгәндә катлаулы булмаган шартны хәтерендә тотып тора ала.

Авазлар әйтелеше һәм дикция яхшыра. Сөйләм балаларның активлыкларын үстерә. Алар хайван тавышлары чыгаралар. Теге яки бу персонажны сөйләмен интонация белән аерып күрсәтә алалар. Сөйләмнең ритмик төзелеше, рифмасы игътибарга лаек. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш ала. Балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыгалар. Бер – берсе белән аралашканда балаларның сөйләме ситуациягә бәйле, ә олылар белән аралашканда ситуациягә бәйләнмәгән була.

Бала белән олыларның аралашу эчтәлеге үзгәрә. Ул бала эләккән конкрет ситуациядән читкә тайпыла. Танып белү мотивы алга чыга. Аралашу процесында алган мәгълүмәтләр бик үк аңлашылып бетмәсәләр дә, балада кызыксыну уяталар.

Бала өлкәннәрнең үзен ихтирам итүләрен тели, мактау сүзе аның өчен бик зүр әһәмияткә ия була бара. Бу баланың артык үпкәләүчән булуына китерә. Шелтә, кисәтүләргә тискәре мөнәсәбәт туа. Артык үпкәләүчәнлек бу яшьнең феномены булып тора.

Яшьтәшләре белән бала сайлап кына аралаша башлый. Ул кайбер иптәшләренә өстенлек бирә. Уен вакытында даими партнерлар барлыкка килә. Төркемдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышу барлыкка килә. Ярышу үзенең башкалар белән чагыштыру өчен әһәмиятле. Бу үз чиратында Мин образының үсешенә, аны детальләштерүгә китерә.

Бу яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсү; рольле һәм тормышчан узара бәйләнешләр барлыкка килү; сүрәтләү эшчәнлеге үсү; үзен уйлап конструкцияләү; планнаштыру зиһенгә алу сәләте камилләшү образлы, хыялый фикерләү, танып белүдә мин – минлек (минеке генә дөрес дигән позиция); хәтер, игътибар, сөйләм, дәлилли белү сәләте үсү, олыларның хөрмәтенә ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, ярышу кебек сыйфатлар барлыкка килү, Мин образның үсүе белән характерлана.

**Тәрбия һәм белем бирү бурычлары**

Балаларның сәламәтлеген ныгыту, организмнарын чыныктыру эшен дәвам иту, төп хәрәкәтләрне дөрес итеп башкару күнекмәләре формалаштыру. Барлык төр эшчәнленлектә гәүдне дөрес тотарга гадәтләндерү. Хәрәкәт эшчәнлегендә мөстәкыйльлек һәм иж,адилык тәрбияләү. Культура-гигиена кунекмәләре булдыру.

Балаларың күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлыкларын арттыру, аларны иж,тимагый тормыш, табигать предметлары, күренешләре белән таныштыруны дәвам иттерү. Предметлар-ның һәм тере объектларның аерым өлешләрен һәм характерлы билгеләрен (төсе, формасы, зурлыгы) аерып курсәтә белергә, аларны шул билгеләргә карап чагыштырырга, теркемәргә аерырга өйрәтү. Предметлар һәм күренешләр турында гомуми кузаллау формалаштыру, алар арасында иң гади бәйләнешләр урнаштырырга өйрәтү.

Балаларның педагоглар белән конкрет ситуация чикләреннан чыккан мәгълуматларны уртаклашасы килу теләкләрен канәгатьләндерү. Аларньщ фикерләренә артык таләпчән булмау.

Туган йортка, туган якка балалалар бакчасына мәхәббәт тәрбияләуне дәвам итү.

Балаларның сүзлек запасын баету, активлаштыру, авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, сөйләм культурасын камилләштерү өстендә эшне дәвам иту. Бирелган тема буенча әңгәмәдә актив катнашырга, үз тәжрибәләреннан чыгып, уенчыклар турында, сюжетлы рәсемнар буенча хикәялар төзергә ярдәм итү.

Якын кешеләренең һөнәрләре белән таныштыру, хезмәтләренең мөһимлеге турында аңлату. Үзләренең хезмәт күнекмәләрен камиллаштеру.

Эшне төгәл үтәргә, башлаган эшне ахырына ж,иткерергә, үз хезмәтенең башкалар өчен әһәмиятен аңлый белергә өйрәтү.

Балаларда тыйнаклык, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; гадел, көчле, кыю булырга теләк, омтылыш булдыру; ямьсез кыланышлары өчен ояла белу сыйфаты тәрбияләү (ямьсез кыланышларын башкалар алдында бәяларга ярамый, чөнки биш яшьлек балалар бик үпкәләүчән булалар). Еш мактау, өлкәннәрне нәрсә белән сөендерүләрен, гаж,әпкә калдыруларын аңлату.

Уенчыкларга, китапларга, башка әйберләргә сак мөнәсәбәт тәрбияләү.

Балаларньң әйләнә-тирәдәге матурлыкны күрә белүләрен, табигатьтә, көнкүрешта, уен вакытларында әхләкый нәфасәти тойгыларын үстерү .

Сәнгать әсәрләренең эчтәлегенә төшенә, музыка,әкият, хикәяләрне игътибар белән тьңлый белүләренә ирешү.

Сәнгатьнең төрле төрларенә кызыксыну тәрбияләү. Рәсем ясаганда, әвәләгәндә, төрле әсәрләрне сәхнәләштергәндә балаларньң образга керә алу сәләтләрен үстерү; шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә, ж,ырларга, бию хәрәкәтләрен көйгә туры китереп башкарырга өйрәтү. Бәйрәмнәр, күңел ачу чаралары вакытында балаларны мәдәни жәүһәрләр белән таныштыру, ж,әмгыятьтә аралаша белү кунекмәләре формалаштыру.

**Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге:** барлыгы атнага – 10 шөгыль, дәвамлылыгы – 20 мин.

| Юнәлешләр | Белем бирү өлкәләре, максатлары |
|---|---|

| | |
|---|---|
| *Физик үсеш* | **Физкультура**<br>Балаларда физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру |
| *Социаль шәхес үсеше* | **Социальләштерү**<br>Балаларның социаль характердагы беренчел күаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирә бурычларын билгели. |
| | **Хезмәт**<br>Балаларда хәзмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру |
| *Танып- белү* | **Танып белү**<br>Балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү |
| *Сөйләм үсеше* | **Аралашу**<br>Әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чараларын үзләштерү |
| | **Матур әдәбият белән таныштыру**<br>Балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ, формалаштыру |
| *Нәфис- нәфасәти үсеш* | **Иҗади сәнгать**<br>Балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уяту һәм үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерү формалаштыру |
| | **Музыка**<br>Балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү |

**Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге:**

1. Физкультура
2. Танып белү
- иң гади математик күзаллаулар формалаштыру;
- әйләнә-тирә белән таныштыру;
- конструкцияләү(режим вакытында).
3. Матур әдәбият
4. Аралашу:
- сөйләм үстерү;
- рус теленә өйрәтү(режим вакытында).
5. Иҗади сәнгать:
- рәсем ясау;
- әвәләү
- кисеп ябыштыру
6. Музыка

**“Танып белү”(иң гади матиматик күзаллауларын булдыру) белем бирү өлкәсе**

“Танып белү” белем бирү эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели. Бала дүрт-биш яшькә җиткәч, аның аңында формалашкан дөньяны кабул итү, образлы фикерләү һәм күзаллау, танып белү эшчәнлегендә эгоцентрик позиция алга чыга; хәтер, игътибар, сөйләм, танып белү мотивацияләренең үсеше күзәтелә башлый.

Биш яшькә җиткәндә, бала аңында, максатчан тәрбия, белем бирү һәм аның үз тәҗрибәсе баюы нәтиҗәсендә, күләм, зурлык, предметларның формасы, пространство һәм вакыт турында төгәл күзаллаулар байлыгы формалаша. Уртанчылар төркемендә балалар күләм мөнәсәбәтләренең мәгънәсен тулырак аңлый башлыйлар. Сөйләм, ишетү, хәрәкәт образлары аша аңлатканда, 4-5 яшьлек бала аңында натураль саннарны ишетеп кабул итү формалашып җитә. Ул, гадәттә, пространстволы була. Сүз-саннар, бер рәткә тезелеп, тәртип буенча әйтелә башлыйлар. Бу эшләр эзлекле рәвештә башкарылырга тиеш. Әлеге вакыт аралыгында исәп бер рәвешле була. Балалар, сүз-саннарны предметларга күрсәтеп: «бер» (берәү мәгънәсендә), «ике», «өч», «башка» (икенче), «өченче» һ. б. дип атыйлар. «Күпме?» дип.сорасаң, алар тагын саный башлыйлар. Санау эшчәнлеген үзләштерүнең башлангыч этабында һәр балага да шушындый үзенчәлекләр хас була. Алар санау процессын (саннарның атамаларын, аларның предметларга карауларын) үзләштерсәләр дә, гадәттә, соңгы аталган сүз-санны бөтен күплек белән бәйли алмыйлар. Болай санау «нәтиҗәсез» дип атала (Н. А. Менчинская).
Дүрт (кайчакта биш) яшьлек балалар, санарга өйрәнгән вакытта, «Дүрт санына кадәр нинди сан килә?» «Ә аннан соң нинди сан?» дигән сорауга тиз генә җавап бирә алмыйлар. Алар йә бармакларын бөгеп саный, йә «кадәр», «соң», «алдында», «артында» сүзләрен кулланып искә төшерә башлыйлар. Бергә артыграк булган санны әйтергә сораганда, алар күңелдән, йә телдән бөтен рәткә караган сүз-саннарны әйтеп чыгалар. Балалар һәр яңа санның алдагысына караганда зур-рак булуын аңлыйлар, әмма билгеле бер санны аерым гына күзаллый алмыйлар.
Күплекне зурайту, кечерәйтү яки саннарны кушу, алуны 4-5 яшьлек бала предметларга башка предметларны өстәп кенә башкара ала. Ул үз эшен һәм аның нәтиҗәсен сөйләп эшли.
Сөйләм уен шартларында активлаша. Әмма күплекне билгеләгәндә, (урындыкларга караганда уенчыклар күбрәк) балалар аның санау күп-легенә яки билгеле бер санның алдында (артында) торуына карап эш йөртәләр. Шулай итеп, балалар һәр санның (5,10 аралыгында) берәр берәмлеккә арта яки кими баруы нәтиҗәсендә барлыкка килүен тиешле дәрәҗәдә үзләштереп өлгерәләр. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар (уртанчылар төркеме) төрле зурлыкларны бер әйберне икенчесе өстенә кую һәм бер әйберне икенчесе янына кую юлы белән билгелиләр. Дүрт яшькә җиткәндә, зурлыкларның төрле булуын аңлыйлар һәм авырлыкны, зурлыкны, предметларның башка сыйфатларын (төс, форма) аера башлыйлар.

Дүрт-биш яшьләрдә геометрик фигуралар аналитик кабул ителә башлый, аларга хас сыйфатлар, үзенчәлекләрне, аларның структурала-рын балалар эмпирик юл (тәҗрибә юлы) белән билгелиләр. Геометрик фигураны контур буйлап бармакларын йөртеп өйрәнәләр. Бу яшьтә бала аңында фигураларның образлары формалаша. Алар предметларны геометрик фигуралар белән чагыштырып өйрәнә башлыйлар. Таныш түгел форманы ачыклау өчен, билгеле эталоннар кулланалар. Балаларга безне әйләндереп алган материаль дөньяның формаларын, аларның үзенчәлекләрен өйрәнү бик тә кызык. Алар бу фигураларны чагыштыралар, охшашлык һәм аермалыкларын күрсәтәләр, билгеле бер тәртипкә китерәләр. Хәзерге көндә балалар өчен тәкъдим ителгән дидактик әсбаплар, уенчыклар бик күп. Алар балаларның геометрик фигураларны актив өйрәнүгә булган омтылышын тормышка ашыра. Мисал өчен: геометрик фигуралардан торган җыелмалар, Дьенешның геометрик блоклары, геометрик фигуралы уеннар, төрле модельләр, «Төс һәм форма», «Фомра һәм зурлык» җыелмалары һ. б.
Бу яшьтә фигураны аерып торучы сыйфат буларак, аның контурын күреп билгели алу мөһим. Шуңа да, фигураларны абстракцияләү өчен, аларның модельләрен кулланалар. Бу модельләргә фигураларга хас форма, зурлык, төс һәм башка сыйфатлар бирелә. Балалар бу сыйфатларны кодлаштыра, шуның нәтиҗәсендә аларның мөстәкыйль уеннары байый, иҗади күзаллаулары үсә, билгеле бер геометрик закончалыкларны аңлау мөмкинлеге туа.

Балаларга, үз белемнәрен кулланып, тирәлекләрендәге предметлар һәм аларның аерым

өлешләренең формаларын аерып өйрәнү кызыклы. Шуңа да, аларның иҗади мөстәкыйльлеген үстерү өчен, яннарындагы предметлар турындагы сорауларны ешрак бирергә кирәк. «Мин нәрсә күрәм?» дигән сорауга җавап бирер өчен, алар, предметларны өйрәнгәндә, тагын да игътибарлырак булачаклар.

Дүрт-биш яшьлек балаларда тәүлек һәм аның өлешләре турындагы күзаллауларны да формалаштырырга кирәк. «Кичә», «бүген», «иртәгә» дигән сүзләрнең мәгънәләре белән таныштырырга кирәк. Моның өчен бала тормышындагы бик тә мөһим бер вакыйга турында өч тапкыр сөйләшү әйбәт булачак: башта курчак театрына иртәгә бару турында; аннары курчак театрына бүген барачакбыз; һәм, ниһаять, аны кичә күрсәттеләр дип әйтү кирәк. Шуның нигезендә бала вакытның туктаусыз алга баруын һәм өзлексез булуын аңлаячак.

Бу яшьтәге балалар модельләштереп аңлатуны да адекват рәвештә кабул итәләр. Модельләрне практик эш барышында куллану, шулай ук аларны балалар белән бергә әзерләү дә отышлы булачак.

Дүрт-биш яшьлек балаларның пространствода ориентлашу күнекмәләре дә үсештә була: алар юнәлешләрне үзләреннән чыгып билгелиләр, күрсәтелгән юнәлештә хәрәкәт итә алалар, предметларның үзләреннән кайсы якта урнашуын әйтә алалар. «Ерак», «якын» төшенчәләрен төгәл аңлау да формалаша. Билгеле бер модель булган а пространстволы мөнәсәбәтләрне дә куллана беләләр: мәсәлән, уенчыкны эзләгәндә, махсус план куллану бик уңышлы. Предметның план һәм бүлмәдә ничек урнашуын чагыштырып карыйлар, җиһазларның планда ничек сызылган булуын игътибар белән өйрәнәләр.

Мәктәпкәчә яшьтәге уртанчылар төркеменә караган балаларның төп үзенчәлеге шунда: аларның аңында бара торган психик процесслар һәрвакыт хәрәкәттә һәм бик тә сыгылмалы. Математик белемнәрнең үсеше олылар тарафыннан тудырылган белем алу шартларына турыдан-туры бәйле. Балалардагы гадәти математик күзаллауларны үстерү эшен оештырганда, аларга хас танып белү эшчәнлеге мөмкинлекләрен һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотарга кирәк.

ПЕРСПЕКТИВ ПЛАНЛАШТЫРУ

| Ай исеме | № | Эшчәнлек барышы темасы | Программ эчтәлек |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | 1 | Күп, бер. Зур, кечкенә. | 1. Төркемнән билгеле предметларны аерып алу һәм аларны яңадан төркемнәргә берләштерә белү күнекмәләрен ныгыту; төркемдәге барлык предметларга хас сыйфатларны һәм аерым бер предметларга гына хас сыйфатларны табарга өйрәтү, күп һәм аз предметларны таба белү күнекмәләрен булдыру, предметларны зурлыкларына карап чагыштырырга һәм нәтиҗәләрне «зур», «кечкенә», «зуррак», «кечерәк» сүзләре белән атарга өйрәнү.<br>2. Балаларда игътибарлылык, кабул итү һәм логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Тырышлык, активлык һәм биремнәргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | 2 | Күп, бер. Көн, төн. Алда, артта, сулда, уңда, өстә, аста. | 1. Махсус әзерләнгән урында бер һәм күп предметларны табу күнекмәләрен ныгыту; бер төркем уенчыклар янына шулкадәр үк башка төрле уенчыкларны куярга өйрәтү; уенчыкларны, уң кулга алып, сулдан уңга күчерергә өйрәтү; тәүлек өлешләре турындагы күзаллауларны тирәнәйтү.<br>2. Игътибар, сөйләм, чагыштыру буенча фикерләү операцияләрен, анна- лизны, иҗади мөмкинлекләрен, пространствода ориентлашуны үстерү.<br>3. Дәресләрдә укуга омтылыш тәрбияләү, табигатьне сакларга һәм якларга өйрәтү. |
| | з | кечерәк. Түгәрәкләр һәм квадратлар. Төркемнәрдәге предметларны тоемлау хисләренә таянып чагыштыру. | 1. Ике төрле җыелманың кайсысында предметларның күбрәк, кайсысында әзрәк яки алардагы предметлар санының тигезме-юкмы икәнлеген билгеләү. Бу очракта предметларны берсе өстенә икенчесен куеп карау һәм предметларны янәшә кую юлы белән тикшерү, предметларны уң кулга алып, балаларда сулдан уңга күчереп кую күнекмәләрен камилләштерү; түгәрәк һәм квадратларны дөрес атарга һәм аерырга өйрәтү, балаларны «никадәр», «шулкадәр», «тигез», «күбрәк», «әзрәк» сүзләрен кулланырга өйрәтү. Авазларны һәм хәрәкәтләрне санамыйча гына, өчәр тапкыр кабатларга күнектерү.<br>2. Логик фикерләүне, игътибарны, тапкырлык һәм ритмны тоя белү сыйфатларын үстерү.<br>3. Башкаларга ярдәм итү теләген тәрбияләү. |
| | 4 | Бертигез, никадәр, шулкадәр; зуррак, кечерәк. Квадрат һәм өчпочмак. Озын, кыска. | 1. Ике төркемгә караган предметларны «бертигез», «никадәр», «шулкадәр», «зур», «кечкенә» төшенчәләренә нигезләнеп чагыштыру; квадрат һәм өчпочмакларны үзара аеру буенча күнегүләр уздыру. Ике предметны озынлыклары һәм кыскалыклары буенча чагыштырырга өйрәтү.<br>2. Игътибарны, хәтерне, бәйләнешле сөйләмне, күзәтүчәнлекне үстерү.<br>3. Бөҗәкләргә игътибарлы караш тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Октябрь | 5 | 2 санының оешуы. Уң, сул. | 1. Балаларны 1 һәм 2, 2 һәм 3 предметтан торган төркемнәрнең предметларын бермә-бер янәшә куйганнан соң аерырга өйрәтү; тәрбияче санап чыкканнан соң, предметларның гомуми санын әйтергә өйрәтү; карап чагыштырганнан соң, кайсы санның зуррак, кайсысының кечерәк булуын әйтеп бирү; үз-үзеңә карап, юнәлешләрне билгеләргә өйрәнү (уң, сул куллар, аяк табаннары һ.б.)<br>2. Сөйләм, фикерләү, игътибар, тирәлекне кабул итү сәләтен үстерү.<br>3. Танып белүгә кызыксыну, дуслык мөнәсәбәтләрен, тырышлык, пөхтәлек, чәчәкләргә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| Октябрь | 6 | 2 саны. Уңга, сулга, алга, өскә. | 1. 1 һәм 2. 2 һәм 3 предметтан торган төркемнәрне аерырга өйрәтү, тәрбияче әйткән сан буенча алдагы предметларның санлы нисбәтен үзгәртү; юнәлешләрне күрсәтә белү күнекмәләрен ныгыту; уңга, сулга, алга, өскә юнәлешләрен аерып белдерү.<br>2. Балаларда күрү хәтерен, логик фикерләүне, вак моториканы, бирелгән сорауга җавап бирү күнекмәләрен ныгыту.<br>3. Уку эшчәнлегенә ияләштерә башлау: тәрбиячене һәм җавап бирүче иптәшләреңне бүлдермәскә өйрәтү, урыннан кычкырып утыруның дөрес түгеллеген аңлату. |
| | 7 | 3 кә кадәр санау. Геометрик фигуралар. | 1. Балаларны өчкә кадәр санарга өйрәтү, саннарны тәртип буенча атау, предметларны тәртип буенча күрсәтә белү. Соңгы санның бөтен төркемгә каравын һәм аның барлык предметларның гомуми санын белдерүен аңлату; предметларны уң кул белән тотып санау һәм аны сулдан уңга күчереп куярга өйрәтү. Геометрик фигуралардан Крошның (махсус үрнәк буенча) рәсемен җыю, геометрик фигураларны танырга өйрәтү.<br>2. Сөйләмне, фикерләүне, күзаллауны, игътибарны, сенсор мөмкинлекләрне үстерү.<br>3. Балаларда танып белүгә кызыксыну, дуслык, тырышлыкка хөрмәт тәрбияләү. |
| | 8 | 3 кә кадәр санау. Предметларны иңе, буе, калынлыкларына карап чагыштыру. | 1. 1 Һәм 2,2 Һәм 3 предметтан торган җыелмаларны аера белү күнекмәләрен ныгыту; «зуррак», «кечерәк», «тигез» төтшенчәләрен яңларга өйрәнү: 3 кә кадәр санау күнекмәсен булдыру; балаларны иңе, буе, калынлыклары төрле булган предметларны аерырга өйрәтү. «Киңрәк», «таррак», «киң», «тар» төшенчәләрен аңлаткан күнегүләрне эшләү.<br>2. Логик фикерләүне, тапкырлыкны, игътибарлылыкны үстерү.<br>3. Башкаларга ярдәм итү теләген тәрбияләү; биремнәрне ахырына кадәр тыңлап бетерү һәм төгәл итеп үтәү күнекмәләре тәрбияләү. |
| Ноябрь | 9 | 4 санының оешуы. Түгәрәк, квадрат, өчпочмак. Алга, артка, сулга, уңга, өскә, аска. | 1. Балаларны 4 саны белән таныштыру; 4 кә кадәр санарга; геометрик фигураларны аерырырга өйрәтү (түгәрәк, квадрат, өчпочмак), юнәлешләр белән бәйле күнегүләр уздыру (алга, артка, сулга, уңга, өскә, аска).<br>2. Фикерләүне, игътибарны, хәтерне үстерү.<br>3. Балаларда математикага кызыксыну тәрбияләү. |
| | 10 | 4 кә кадәр санау. Алда, артта. | 1. 4 кә кадәр санау күнекмәсен ныгыту; нинди яшелчәләр барлыгын һәм аларның күпме булуын сөйләргә өйрәтү, карточкаларда ясалган яшелчә һәм түгәрәкләрнең бер үк санда икәнлеген күрсәтә белү; балаларны карточкаларда ясалган түгәрәкләр санынча уенчыкларны табарга өйрәтү; фотографияләрдә күрсәтелгән предметларның юнәлешләрен (алда, артта) билгеләү буенча күнегүләр уздыру.<br>2. Игътибарны, хәтерне үстерү.<br>3. Математика фәненә кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 11 | 5 санының оешуы. Озынрак, кыскарак. | 1. Балаларга 5 санының барлыкка килүен аңлату, аның белән таныштыру; предметларны озынлыкларына карап чагыштыра белү күнекмәләрен ныгыту; «озынрак», «кыскарак» сүзләрен куллану; предметларны үрнәккә карап санау күнегүләрен эшләүне дәвам итү; предметларны «зуррак», «кечерәк», «тигез» сүзләрен кулланып чагыштыру.<br>2. Кулларның вак моторикасын үстерү.<br>3. Дуслык мөнәсәбәтләрен, ярдәмгә килү теләген, математика дәресләренә кызыксыну тәрбияләү. |
| Ноябрь | 12 | 5 кә кадәр санау. Төрле ераклыкларда урнашкан предметларның санын билгеләү. Түгәрәк. | 1. 5 саны турында аңлатма бирү; балаларны 5 кә кадәр санарга өйрәтү; предметларның ераклыклары төрле булса да, саны тигез булуын күрергә өйрәтү; түгәрәк турындагы күзаллауны ныгыту, «зур», «кечкенә» сүзләрен куллану.<br>2. Хәтерне, сөйләмне, күзаллауны, музыкаль сәләтне үстерү.<br>3. Үзеңнең сәламәтлегеңне кайгырту күнекмәләрен булдыру. |
| Декабрь | 13 | Әйтелгән санга туры китереп, предметларны санарга өйрәнү. Ерак, якын. | 1. Алдан әйтелгән санга туры китереп, предметларны санарга өйрәнү: 5 кә кадәр санау күнемәләрен ныгыту; түгәрәк, квадрат, өчпочмакны аера белергә һәм дөрес әйтергә өйрәтүне дәвам итү; бу фигураларны төсләренә, зурлыкларына һәм пространствода төрле урында урнашуларына бәйсез рәвештә танырга өйрәтү; «ерак», «якын» төшенчәләре белән таныштыру.<br>2. Игътибарны, хәтерне, фикерләүне, тапкырлыкны, уку эшчәнлеге күнекмәләрен үстерү.<br>3. Яшьтәшләреңне, кызмы, малаймы булуына карамастан, хөрмәт итәргә өйрәтү. |
| | 14 | Озын, кыска, озынрак, кыскарак. Күбрәк, азрак. | 1. Чагыштыруларга нигезләнеп, балаларны предметларның озынлыгын билгеләргә өйрәтү; предметларның зурлыклары турындагы күзаллауларны формалаштыру (озынрак, кыскарак, озын, кыска, озынлык); «озынрак», «кыскарак», «озын», «кыска»  «озынлык» сүзләре кергән күнегүләрне эшләү; санарга өйрәтүне дәвам итү.<br>2. Логик фикерләүне, хәтерне, игътибарны үстерү.<br>3. Ярдәмчеллек, пөхтәлек, математикага кызыксыну тәрбияләү. |
| | 15 | Киңрәк, таррак. Озынрак, кыскарак. 5 кә кадәр санау. | 1. Чагыштыруларга нигезләнеп, балаларны предметларның киңлекләрен аерырга өйрәтү; бер әйберне икенчесе янына кую юлы белән аларның иңнәрен һәм буйларын чагыштырырга өйрәтү; «озынрак», «кыскарак», «озын», «кыска», «озынлык» сүзләрен кулланырга өйрәтү; 5 кә кадәр санау күнегүләрен башкару.<br>2. Күз белән карап үлчәү эшчәнлеген, игътибарны, логик фикерләүне, сөйләмне үстерү.<br>3. Башкаларга карата игелекле булуны тәрбияләү. |
| | 16 | Турыпочмаклык. 5 кә кадәр санау. Иңе, буе төшенчәсе. | 1. Балаларны турыпочмаклык белән таныштыру һәм аларны турыпочмаклык, квадрат, өчпочмакны аерырга өйрәтү; балалар белән 5 кә кадәр санауны дәвам итү; балаларны күз белән карап һәм бер әйберне икенчесе янына куеп карау юлы белән иңе, буе бер үк булган предметларны табарга өйрәтү.<br>2. Балалардагы игътибарлылыкны һәм иҗади сәләтне үстерү.<br>3. Башланган эшне ахырына кадәр җиткерә белү сәләтен һәм тырышлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Гыйнвар | 17 | Үрнәк фигурага карап санарга өйрәнү. Түгәрәк, квадрат, турыпочмак-лык һәм өчпочмак. | 1. Үрнәктәге түгәрәкләр санынча предметларны санап алырга өйрәтү; түгәрәк, квадрат, турыпочмаклык һәм өчпочмакны аера белү буенча күнегүләрне башкаруны дәвам итү.<br>2. Игътибарны, зирәклекне, уйлап табуны, фикерләүне, сөйләмне үстерү. 3. Кызларда - нәзакәтлелек, матурлык, малайларда кыюлык, батырлык, пөхтәлек, тырышлык тәрбияләү. |
| | 18 | Аралары төрле булган предмет төркемнәрен чагыштыру. Иңе, буе, биеклеге. | 1. Төрле зурлыктагы предметларның тигез саннардагы төркемнәрен бул-<br>дыру, балаларга предметларның саны аларның зурлыкларына бәйле тү-геллеген аңлату; 5 кә кадәр санау күнекмәләрен ныгыту; предметларны иңе, буе, биеклеге һәм күләмнәренә карап чагыштыру күнегүләрен башкару.<br>2. Игътибарлылыкны, хәрәкәтчән осталыкны, логик фикерләүне ныгыту.<br>3. Шөгыльләнүгә, башкаларга ярдәм итүгә теләк тәрбияләү. |
| Гыйнвар | 19 | Предмет зурлыгының саннан бәйле түгеллеге. Иңе, буе, биеклеге. | 1. Төрле үлчәмдәге предметларны үз эченә алган төркемнәр арасында тигезлек һәм тигезсезлек билгеләрен куярга өйрәнү; балаларга предметларның саны аларның зурлыгына бәйле түгеллеген аңлату; предметларны аларның иңенә, буена карап чагыштырырга өйрәтү; төрле төрдәге зурлыкларны үзара чагыштырып карау.<br>2. Игътибарны, хәтерне, сөйләмне, фикерләүне, күзаллауны үстерү.<br>3. Белем алуга кызыксыну тәрбияләү. |
| | 20 | Предметлар формасының саннан бәйле түгеллеге. 5 кә кадәр санау. Озынрак, кыскарак. Ераграк, якынрак. | 1. Төрлечә урнаштырылган предметларның бер үк санда булуын күрергә өйрәтү; нинди дә булса фигура барлыкка китергән предметларның исәбен алып барырга һәм шул ук сандагы предметларны бер рәткә яки башка фигура сыйфатында тезәргә өйрәтү; предметларның озынлыгын чагыштыру һәм «озынрак», «кыскарак», «ераграк», «якынрак» кебек төрле төрдәге мөнәсәбәтләр арасында бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Игътибарны, сөйләмне, фикерләүне, иҗатка булган сәләтне үстерү.<br>3. Мөстәкыйльлек, пөхтәлек, бер-береңә карата игелекле мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| Февраль | 21 | Предметлар санының урнашу формасына бәйле түгеллеге. 4 кә кадәр санау. Ераграк, якын-рак. | 1. Төрлечә урнаштырылган предметларның бер үк санда булуын күрергә өйрәтү; бер рәткә генә тезелгән түгел, ә берәр кызыклы формада урнаштырылган фигураларны санарга өйрәтү; «якын», «ерак» төшенчәләре турында күзаллауларны ныгыту.<br>2. Хәтерне, игътибарны, логик фикерләүне, кулларның вак моторикасын үстерү.<br>3. Башкалар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| | 22 | Предметлар санының ераклыкка бәйле түгеллеге. Уңда, сулда. 5 эчендә санау. | 1. Предметлары үзара төрле аралыкта урнаштырылган төркемнәр арасында тигезлек һәм тигезсезлекне билгеләү; предметларның үз-үзеңнән кайсы якта урнашуларын күрсәтергә өйрәнү (уңда, сулда); предметларны бишкә кадәр санау.<br>2. Хәтерне, игътибарны, логик фикерләүне үстерү.<br>3. Кошларга карата мәхәббәт һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 23 | Өч предметны озынлыкларына нисбәтле чагыштыру. 5 кә кадәр санау. Предметлары үзара төрле ераклыкта урнаштырылган төркемнәр арасында тигезлекне билгеләү. | 1. Өч предметны озынлыкларына нисбәтле үзара чагыштырырга өйрәтү; предметларны озынлыклары артуга бәйле рәвештә бер рәткә тездерү; «иң озын», «иң кыска», «озынрак», «кыскарак» сүзләрен кулланырга өйрәтү; бишкә кадәр санау.<br>2. Сөйләмне, фикерләүне, игътибарны, тапкырлыкны үстерү.<br>3. Балалар арасында дуслык мөнәсәбәтләре, белем алуга кызыксыну, тырышлык, биремнәрне үтәгәндә, пөхтәлек тәрбияләү. |
| Февраль | 24 | Предметлары үзара төрле сраклыкта ур-наштырыл ган төркемнәр арасында тигезлек һәм тигезсез-лекне билгеләү. 5 эчендә санау. Тәбәнәк, биек. | 1. Предметлары үзара төрле ераклыкта урнаштырылган төркемнәр арасында тигезлек һәм тигезсезлекне билгеләргә өйрәтү; озынлыклары буенча үзара тигез у башкалардан озынрак, кыскарак предметларны аерып алырга өйрәтү; предметларны озынлыклары арта бару тәртибендә тезәргә өйрәтү, тәбәнәк һәм биек предметларны карап чагыштыру.<br>2. Игътибарлыкны, карап чагыштыру күнекмәләрен үстерү. |
| Март | 25 | Иң тар, бераз киңрәк, бик киң. 5 кә кадәр санау. | 1. Өч предметны киңлекләренә карап чагыштыру, киңлекләре арта бару нисбәтле аларны бер рәткә тезү. «Иң тар», «бераз киңрәк», «иң киң» төшенчәләрен аңлату; 5 кә кадәр санарга өйрәтү.<br>2. Игътибарны, күз белән карап үлчәү күнекмәләрен ныгыту.<br>3. Әйберләргә карата игътибарлылык тәрбияләү. |
| | 26 | 5 кә кадәр санау. Үрнәккә карап санау. Киңлек. | 1. Үрнәккә карап, бишкә кадәр санау күнегүләрен башкару; предметлар-<br>ны геометрик үрнәкләргә охшатып сайлап алырга өйрәтү; предметларны<br>киңлекләре арту буенча бер рәткә тезәргә өйрәтү күнегүләрен дәвам итү.<br>2. Логик фикерләүне, игътибарны үстерү.<br>3. Башкаларга ярдәм итү теләген һәм пөхтәлекне тәрбияләү. |
| | 27 | Калын, нечкә, бик нечкә. Предметлары үзара төрле аралыкта урнаштырылган төркемнәр арасында тигезлек һәм тигезсезлекне билгеләү. | 1. Өч предметны калынлыкларына карап чагыштыру, калынлыклары арта бару нисбәтле аларны бер рәткә тезү. «Бик калын (нечкә)», «калынрак (нечкәрәк)», «иң нечкә» сүзләре белән төрле зурлыкларны билгеләү; предметлары үзара төрле аралыкта урнаштырылган төркемнәр арасында тигезлек һәм тигезсезлекне билгеләүне өйрәтү эшен дәвам итү.<br>2. Игътибарны, хәтерне, тапкырлыкны, сөйләмне, күз белән карап, предметларның үлчәмен билгеләү сәләтен, фикерләүне үстерү.<br>3. Математика белән кызыксыну, үзара ярдәмләшү, җавап бирү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | 28 | Бармаклар белән капшап исәпләү. Калын, нечкәрәк, бик нечкә. | 1. Балаларны предметларны капшап санарга, аларның исәбен билгеләр-гә өйрәтү; предметларның калынлыкларына карап, аларны чагыштыру.<br>2. Күрсәтмәле-тәэсирле фикерләүне үстерү, уку эшчәнлегенә кызыксыну<br>уяту, вак моторика күнегүләрен уздыру.<br>3. Башкаларга карата игелекле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мөнәсәбәт һәм ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| Апрель | 29 | Биек, тәбәнәк, биегрәк, тәбәнәгрәк. Үрнәк нигезендә пред-метларны санау. Өскә, аска. | 1. Балаларны 3 предметны, биеклекләренә карап, тәбәнәю һәм биегәю тәртибендә бер рәткә тезәргә, «иң биек», «иң тәбәнәк», «биегрәк», «тәбәнәгрәк», «биеклек» сүзләрен кулланырга өйрәтү; предметларны үрнәккә карап санау күнекмәләрен ныгытуны дәвам итү; «зуррак», «кечерәк», «тигез» сүзләрен кулланып чагыштыру; үзеңнән чыгып тирәлек юнәлешләрен билгеләү (өскә, аска).<br>2. Кулларның вак моторикасын үстерү. Бер-береңә карата дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү, математика дәресләренә кызыксыну уяту. |
| Апрель | 30 | 5 предмет арасында озынлыкла-рына бәйле рәвештә нисбәт урнаштыру. Геометрик фигуралар. 5 кә кадәр санау. | 1. 5 предмет арасында озынлыкларына бәйле рәвештә нисбәт урнаштыру. Озынлыклары кимү һәм үсүгә карап, предметларны бер рәткә урнашты-ру, бу очракта бер кагыйдәгә нигезләнергә: калганнар арасыннан иң озын (кыска) предметларны тәртип буенча сайлап алырга кирәк; предметларның озынлыгын билгеләү өчен, бер предмет янына икенчесен куеп карау юлын куллану күнекмәләрен ныгыту; балалар сөйләмендә «иң озын», «иң кыс-ка», «озынрак», «кыскарак», «озынлык» сүзләрен активлаштыру; предметлар саны аларның урнашу формасына бәйле түгеллеген аңлату, төрле ысуллар белән урнаштырылган предметларны санарга өйрәтү, геометрик фигураларны аерырга өйрәтә торган күнегүләрне эшләү.<br>2. Кулларның вак моторикасын, ирекле игътибарны, тоемлауны, логик фикерләүне, тапкырлыкны үстерү.<br>3. Мөстәкыйльлек тәрбияләү. |
| | 31 | 5 кә кадәр санау. Предметларны биеклекләре буенча чагыштыру. | 1. Балаларны авазларны санарга өйрәтү, ахырдан нәтиҗә санны әйтү күнекмәсен булдыру; дүрт предмет арасында, биеклекләренә карап, бәйләнешләр урнаштыру; биеклекнең кимүе яки артуына карап, предметларны бер рәткә тезү.<br>2. Ритмны тою, кабул итү, конкрет-образлы фикерләү, тизлек, җитезлекне үстерү.<br>3. Рус милли мәдәниятенә һәм белем бирү әшчәнлегенә карата балаларга тәрбия бирү. |
| | 32 | Аталган сан буенча исәп. Геометрик фигуралар. | 1. Балаларны алдан әйтелгән санга кадәр исәпләргә һәм аны хәтердә кал-дырырга, тигез сандагы уенчыкларны табарга өйрәтү; турыпочмаклык, квадрат, өчпочмак һәм түгәрәкне (аларның зур модельләре тәкъдим ителгәндә) аера белү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Тәэсирле кабул итү, пространствода ориентлашуны, конкрет образлы фикерләүне, тизлекне, җитезлекне тикшерү.<br>3. Смешариклар һәм аларның дәресләренә кызыксыну уяту, дуслыкка хөрмәт тәрбияләү. |
| Май | 33 | Предметларны киңлекләренә карап чагыштыру. Бармак-лар белән капшап исәпләү. | 1. Балаларны 5 төрле предметның киңлекләре арту, кимүгә бәйле рәвештә аларны бер рәткә тезәргә өйрәтү; предметларның киңлекләрен чагыштыру өчен, бер әйберне икенчесе янына куеп карау алымын куллану; «иң киң», «иң тар», «киңрәк», «таррак», «тагын да таррак», «тагын да киңрәк» сүзләрен кулланырга күнектерү; предметларны бармаклар белән капшап санарга өйрәнү.<br>2. Кулларның вак моторикасын, күзләр координациясен, мөстәкыйльлекне, активлыкны, игътибарлылыкны үстерү.<br>3. Пөхтәлек һәм дуслыкка хөрмәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
2. К.В.Закирова Балачак аланы. Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти – әниләр өчен хрестоматия. - Казан: РИЦ нәшрияте, 2011

**“Иҗади сәнгать” белем бирү өлкәсе**

“Иҗади сәнгать” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге ма-турлыкка кызыксыну уятуны һәмүз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгать-ләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

**Рәсем ясау**

**Ел ахырына үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр**

- Предмет – күренешләрне карандаш, буяулар, фломастерлар, төсле акбурлар кулланып сүрәтләү, төсләрне дөрес сайлап, пөхтә итеп буяу;
- Бер рәсемдә берничә предметны берләштереп, катлаулы булмаган сюжет төзү.

Дымково, Филимоново уенчыкларынын ачык чагылышлы сүрәтләү чараларын курсәтә белү, китап иллюстрацияләре белән кызыксыну.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № | Тема | Бурычлар | файдаланылган әдәбият | Үткәрелү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Жәй турында рәсем ясау | Балаларны күргәннәрен бер рәсемдә бер эчтәлеккә берләштереп сүрәтләргә өйрәтү. Пумала белән дәрес эш итүне, суда юууны ныгыту. Рәсемнең эчтәлегенә карап предметларны дөрес итеп урнаштыра белергә өйрәнү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 45 бит | Сентябрь 1 атна |
| 2 | Алмалар җитешкән чак | Балаларга агач ясарга өйрәтүне дәвам итү: кәүсәсен, төрле якка үскән озын һәм кыска ботакларын. Карандаш белән ясау ысулларын ныгыту. Рәсемне олы итеп бөтен биткә ясарга өйрәтү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 46 бит | 2 атна |
| 3 | Матур чәчәкләр | Балаларда күзәтүчәнлекне үстерү, ясау өчен предметны сайлый белергә өйрәтү. Пумала һәм буяулар белән эш итү күнекмәләрен ныгыту, эстетик тәрбия бирү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 48 бит | 3 атна |
| 4 | Балалар | Уң кулда пумаланы дөрес тота | Т.С.Комарова Занятия | 4 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | теләге буенча рәсем ясау | белергә өйрәтүне дәвам итү. Рәсемнәрне карап матурларын сайлый белү. Төсләрне аера белергә өйрәтү, уйлау сәләтләрен үстерү. | по изобразительной деятельности в детском саду. | |
| 5 | Алтын көз | Балаларны көз аена хас булган рәсемнәр сүрәтләргә өйрәтү.Техник рәсем ясау алымнарын ныгыту. Пөхтәлеккә тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 49 бит | Октябрь 1 атна |
| 6 | Әкияти агач | Рәсемдә әкияти образны сүрәтләргә өйрәнү; агач ясауны камилләштерү; дөрес итеп буярга өйрәтү, матурлыкны күрә белүне тәрбияләү | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 50 бит | 2 атна |
| 7 | Алъяпкыч бизәү | Тар кәгазьдә гади бизәкләр төзерг өйрәтү. Төс һәм төсмерләрне сурәтләү күнекмәләрен үстерү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 51 бит | 3 атна |
| 8 | Төрле төстәге шарлар | Түгәрәк һәм озынча түгәрәк формаларны ясау күнекмәләре белән танышуны дәвам итү; охшаш һәм аермалы якларын табу; яхшы курсәткечләргә омтылыш тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 55бит | 4 атна |
| 9 | Гади һәм алтын йомыркалар | Эчке форманы, «үткен» төшенчәләрен белү. Овал формаларында рәсем ясарга өйрәтүне дәвам итү. Дөрес буялырга күнегүләр, рәсемнәр. Эчтәлекне тасвирлау. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 53бит | Ноябрь 1 атна |
| 10 | Свитер бизәү | Татар халык орнаменты белән таныштыруны дәвам иту. Декоратив бизәү элементлары: ләлә чәчәге, яфракларны рәсемгә төшеру. Мөстәкыйльлелек тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 55бит | 2 атна |
| 11 | Кечкенә гном | Балаларны рәсемдә бәләкәй кеше образы ясарга өйрәтү, кеше рәсемен сүрәтләгәндә аның өлешләрен дөрес урнаштыру: түгәрәк башы, конуска ошаган күлмәк, конуслы колпачек, туры кулы, зурлыклары буенча нисбәтләрен дөрес күрсәтә белү. Буяулар белән рәсем ясауны | Т.СКомарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 56 бит | 3 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ныгыту.Әзер рәсемнәргә дөрес бәя бирү. | | |
| 12 | Үз теләгең белән рәсем ясау | Рәсемнең темасын сайлап алырга һәм башланган эшеңне ахырына җиткерергә өйрәтү. Каләмне дөрес итеп тотып, рәсемнең кечкенә өлешләрен дөрес итеп буярга күнектерү. Эстетик күзаллау тәрбияләү. | Т.СКомарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 57 бит | 4 атна |
| 13 | Аквариумда балыклар йөзә | Төрле юнәлештә йөзгән балыклар ясау, аларның формасын, канатларын, көйрыгын дөрес күрсәтү. Мөстәкыйльлелек тәрбияләү | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 58 бит | Декабрь 1 атна |
| 14 | Кар кызы | Кар кызын тун белән сүрәтләргә өйрәтү. Гади формаларны ясауны ныгыту; бөтен биткә ясау. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 59 бит | 2 атна |
| 15 | Яңа елга котлау открыткасы | Мөстәкыль рәвештә рәсемнең эчтәлеген уйларга өйрәнү. Пумала һәм буяулар белән чиста, дөрес эш итәргә өйрәтүне дәвам итү. Балаларда мөстәкыльлек һәм инициатива тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 60 бит | 3 атна |
| 16 | Безнең бизәлгән чыршы | Балаларны рәсемнәрдә бизәлгән чыршы ясарга өйрәтү; чыршының ботакларын аска каратып ясау. Төрле төстәге буяулар кулланып ясауны дәвам итү. Матурлыкны күрергә өйрәтү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 60 бит | 4 атна |
| 17 | Кыш көне кечкенә чыршыга салкын | Балаларны рәсемдә гади сюжет ясарга һәм рәсемнәрендә төп эчтәлекне ачарга өйрәтү. Краска, пумала белән чиста эшләргә өйрәтүне дәвам итү. Балаларның күзаллауларын үстерү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 61 бит | Январь 2 атна |
| 18 | Ботаклары асылынган агач | Балаларны нечкә һәм юан ботаклары ясаган вакытта каләм ярдәмендә төрле басым белән басып ясарга кирәклеген аңлату. Яхшы нәтиҗәләргә ирешергә өйрәтү. Балаларның күзаллауларын үстерү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 62 бит | 3 атна |
| 19 | Кулъяулык бизәү (декоратив рәсем) | Балаларны татар халык бизәкләре, нәкышләре белән таныштыруны дәвам итү. Буяу белән нокталар, тамчылар, яфраклар, чәчәк элементлары ясарга өйрәтү. Рәсем ясарга теләк тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 64 бит | 4 атна |
| 20 | Флажоклар | Балаларны турыпочмаклы | Т.С.Комарова Занятия | Февраль |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән тасма бизәү | әйберләр ясарга, аларны буяу белән пөхтә итеп буярга һәм гади композицияләр уйлап табарга өйрәтү. Матурлыкны күрергә өйрәтү. Эстетик сиземләү тәрбияләү. | по изобразительной деятельности в детском саду. 65 бит | 1 атна |
| 21 | Бии торган кыз | Балаларны гади чагыштырулар белән кеше фигурасы: башы кечерәк, гәүдә өлешен зурырак итеп ясарга өйрәтү. Рәсемнәрендә катлаулы булмаган хәрәкәтләр ясау алымнарын ныгыту. Пөхтә итеп эшләргә өйрәтүне дәвам итү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 66 бит | 2 атна |
| 22 | Матур кошчык | Балаларны овал формасы кулланып кошчык рәсеме ясарга өйрәтү; аның каурыйларын дөрес тасфирлау. Пумала һәм буяулар белән ясау алымнарын ныгыту. Күзаллауларын ныгыту. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 67 бит | 3 атна |
| 23 | Матур чәчәкләр | Балаларны күзәтү сәләтен үстерү, татар халык орнаментлары белән таныштыруны дәвам итү. Буяу белән пumalаны дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү. Рәсемнәрне карап матурларын сайлый белү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 68 бит | 4 атна |
| 24 | Матур төзелеш | Балаларны рәсемнәрдә төзелеш күренешен сүрәтләргә, альбом битендә дөрес итеп урнаштырырга өйрәтү. Фигураларны дөрес итеп атауларына ирешү. Пөхтәлек тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 69 бит | Март 1 атна |
| 25 | Курчак күлмәген бизәү (декоратив рәсем) | Таныш булмаган элементлардан (тасма, нокта, түгәрәк) бизәкләр төзергә өйрәтүне дәвам итү. Төрле төсләр кулланып каләмнәр белән мөстәкыйль рәвештә сүрәтләргә өйрәнү. Уйлау сәләтен үстерү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 70 бит | 2 атна |
| 26 | Әкияти өй- теремкәй | Балаларны рәсемнәрдә әкияти сюжетларны сүрәтләргә өйрәнүне дәвам итү. Төсләр сайларга өйрәнү. Пөхтә итеп эшләргә өйрәтүне дәвам итү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 72 бит | 3 атна |
| 27 | Кәҗә бәтие | Балаларны дүртаяклы хайван сүрәте ясарга, аны кәгазь битендә дөрес итеп урнаштырырга өйрәтү. Гәүдә пропорциясен сакларга кирәклеген аңлату. Игътибарлылык тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 73 бит | 4 атна |
| 28 | Салфетка бизәү (декоратив рәсем) | Балаларны шакмакның кырыен, уртасын, почмакларын дөрес итеп кулланып бизәк ясарга өйрәтүне дәвам итү. Үзе ясаган рәсемгә шатлана белү. Активлык | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. | Апрель 1 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тәрбияләү. | 74 бит | |
| 29 | Минем яраткан күрчагым | Балаларны рәсемнәрендә яраткан уенчыкларын ясарга өйрәтүне дәвам итү. Рәсемне бөтен битне тутырып ясарга кирәклеген исләренә төшерү. Төшкән рәсемнәренә соклана белү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 74 бит | 2 атна |
| 30 | Син яшәгән йорт | Балаларны рәсемнәрендә турыпочмаклы итеп йорт һәм тезеп йортның тәрәзәләрен ясарга өйрәт. Алган тәэсирләрдән рәсемне тулыландырырга өйрәтү. Пөхтәлек тәрбияләү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 75 бит | 3 атна |
| 31 | Бәйрәмчә бизәлгән йорт | Бәйрәмчә бизәлгән шәһәр күренешен ясарга өйрәтү. Йортларны рәсемдә бәйрәмчә бизәү. Образлы күзаллауны ныгыту. Төшкән рәсемнәренә соклана белү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 76 бит | 4атна |
| 32 | Болытлар арасыннан очкычлар оча | Балаларны каләмгә төрле басым ясап болытлар арасынан очучы очкычларны ясарга өйрәтү. Образлы күзаллауны ныгыту. Төшкән рәсемнәренә соклана белү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 78 бит | Май 1 атна |
| 33 | Яз турында рәсем ясау | Балаларда яз фасылыннан алган тәэсирләреннән рәсем ясарга өйрәтү. Буяулар белән рәсем ясау алымнарын ныгыту. Уйлау сәләтен үстерү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 78 бит | 2 атна |
| 34 | Үз теләгең белән рәсем ясау | Рәсемнең темасын сайлап алырга һәм башланган эшеңне ахырына җиткерергә өйрәтү. .Каләмне дөрес итеп тотып, рәсемнең кечкенә өлешләрен дөрес итеп буярга күнектерү. Эстетик күзаллау тәрбияләү. | Т.С. Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 79 бит | 3 атна |

**Файдаланылган методик кулланма**


1. Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. М.: Просвещение, 1981.

2. Т.Г.Казакова. Занятия с дошкольниками по изобразительной деятельности. М.: Просвещение, 1995.

**Әвәләү перспектив план**

**Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр**

Өйрәнгән барлык алымнарны кулланып, төрле предметлар һәм уенчыклар әвәләү, аларны коллектив композициягә берләштерү.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № | Тема | Бурычлар | Файдаланылган әдәбият | Үткәрелү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Алмалар һәм җиләкләр. | Түгәрәк формалы предметлар әвәләүне ныгыту. Тирә яктагы хисләрне әвәләүдә күрсәтергә (алмалар һәм җиләкләр пеште). Пөхтә эш итәргә өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 48 бит | Сентябрь 1 атна |
| 2 | Бәләкәй һәм олы кишерләр. | Балаларны озынча формалы предметлар әвәләргә өйрәтү , олы һәм бәләкәй предметлар әвәләү. Ясаган әйберләргә игътибар итү, бәя бирә белү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразигельной деятельности в детском саду. 67 бит. | 2 атна |
| 3 | Кыяр һәм чөгендер. | Овал формалы әйберләр белән таныштыру әвәләү алымнарын ныгыту.Балчыктан әвәләнгән төп формадан аерым кисәкләрне сузарга өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразиьтельной деятельности в детском саду. 69 бит. | Октябрь 1 атна |
| 4 | Балык | Балаларның әвәләү белән кызыксынуларын үстерү.Овал форманы белүне ныгыту.Балыкка хас әйберләр ясау. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 71бит | 2 атна |
| 5 | Гөмбәләр | Таныш предметлар әвәләүне үстерү.Әвәләү алымнарын кулланып пластилинны түгәрәкләп тәгәрәтеп әвәләү .изү кырыйларын чеметеп алу.Ясалган предметларга образлы бәя бирү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 57бит. | Ноябрь 1 атна |
| 6 | Үрдәк. | Әвәләү алымнарына өйрәтү пластилинны сылап изеп тигезләп ясауны.Берничә кисәктән торган предметлар әвәләргә пропорцияләрне саклап кисәкләрне дөрес урнаштырырга өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 62бит. | 2 атна |
| 7 | Кышкы киемдәге кыз. | Берничә кисәктән торган кышкы киемдәге кыз әвәләргә өйрәтү (башы аска таба кинәйгән тун)пропорцияләрне | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной | Декабрь 1 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | дөрес саклап ясаү. | деятельности в детском саду. 63бит | |
| 8 | Үрдәк үрдәк бәбиләре белән | Балчыктан кош гәүдәсен ясарга өйрәтү, овал формалы гәүдәсен ясау, чеметеп һәм сузып вак олешләрен ясау :томшыгын, койрыгын, канатларын мөстәкыйль рәвештә. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 65бит. | 2 атна |
| 9 | Кошчык. | Пластининнан кош гәүдәсен ясарга өйрәтү, овал формалы гәүдәсен ясау, чеметеп һәм сузып вак өлешләрен ясау; томшыгын, койрыгын, канатларын мөстәкыйль рәвештә ясарга өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 70 бит. | Январь 2 атна |
| 10 | Озын тунда кыз. | Балаларны кеше гәүдәсенең гәдәти формаларын бирергә өйрәтү,пропорцияләрне саклау. | Т.С.Комарова. Занятия с дошкольниками по изобразительной деятельности . 67 бит. | 3 атна |
| 11 | Әйлән-бәйлән | Балаларны өлешләрнең чагыштырмасын дөрес итеп, кеше фигурасын сурәтләргә өйрәтергә. Уз эшләрен башка балалар эшләре белән берләштерергә ойрәтергә. Образлар кабул итүне устеру. Дымковский курчак белән таныштыру. | Т.С.Комарова. Занятия с дошкольниками по изобразительной деятельности . 71 бит. | Февраль 1 атна |
| 12 | Чыпчыклар бодай чүплиләр. | Балаларны кошларнын гәүдәсен бодай чүпләгән килеш ясау.Әвәләү алымнарын ныгыту. | Т.С.Комарова. Занятия с дошкольниками по изобразительной деятельности . 71 бит. | 2 атна |
| 13 | Миски. | Балаларны түгәрәк форманы бармак белән батырып кертү, миски ясарга өйрәтү. Кырыйларын сыпырып тигезләү. Эш барышында пөхтәлек тәрбияләү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 71 бит. | Март 1 атна |
| 14 | Кәҗә | Балаларны дүрт аяклы хайванны (сарык җаны, баш, турыдан-туры аяклар) ясауны өйрәтергә. Әвәләүне беркетү: шомарту, йолку һ. б. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности. 78 бит. | 2 атна |
| 15 | Касә | Балаларны төрле ысул белән җәю, салу һәм бармак очлары белән форма бирү, тигезләү ысулларын өйрәту. Беркетү, | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной | Апрель 1 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сыгу һәм шомарту күнегүләрен күнектерү. | деятельности. 78 бит. | |
| 16 | Кош савыттан бөртекләр чупли | Элек үзләштерелгән алымнардан файдаланып, таныш фәннәрне ясый белү: җәелү, тартылу, туры килү, частьләрне тоташтыру, беркетү урыннарын кысып һәм шомартып ныгыту. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности. 78 бит. | 2 атна |
| 17 | Куянчык | Балаларны хайван кисәргә, аның гэйдэсен чын формасын, башын, тешләрен тапшырырга өйрәтергә. Әвәләү һәм өлешләрне тоташтыру ысулларын беркетергә. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности. 78 бит. | Май<br>1 атна |
| 18 | Балалар теләге буенча әвәләү | Әвәләү алымнарын ныгыту. Фантазияләрен үстерү. | | 2 атна |

**Файдаланылган методик кулланма**


1. Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. М.: Просвещение, 1981.
2. Т.Г.Казакова. Занятия с дошкольниками по изобразительной деятельности. М.: Просвещение, 1995.
3. В.Лиштван. Конструрирование. М.: Просвещение, 2000

**Кисеп ябыштыру перспектив план**

**Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр**

*Кайчыны дөрес итеп тотып, турыга һәм диагональ буенча кисү; квадраттан-түгәрәк, турыпочмаклыктан овал кисү ;

*Берничә кисәктән торган предметларнын сүрәтләрен пөхтә итеп ябыштыру;

*Предметның төсләрен туры китереп яисә үз теләгең белән төсләр сайлау;

*Үсемлек орнаменты яки геометрик фигуралар кулланып бизәкләр төзү.

**Эшчәнлекнең тематик планы**

| № | Тема | Бурычлар | Кулланма материал | Үткәрелү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Матур флагчыклар | Балаларны кайчы белән эш итәргә , кисәргә өйрәтү. Пөхтә итеп ябыштырырга, араларны тигез калдырырга өйрәтү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 49 бит | Сентябрь<br>3 атна |
| 2 | Салфетка бизәү. | Квадратта бизәк ясарга, элементларны уртага почмакларга ябыштырырга өйрәтү.Кайчы белән дөрес эш итәргә өйрәтүне дәвам итү. Иҗади сәләт үстерү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 49 бит | 4 атна |
| 3 | Яулык бизәү | Почмакларга өйрәтү. Түгәрәк, квадрат һәм өчпочмак формаларының белү гыйлемен беркетү. Тезмәләр күнегүләрен туплау. Форманы үзгәртеп корырга, өчпочмак һәм ярымтүгәрәк бер квадратны кисәргә өйрәтү. Композицион сәләтләрне үстерү, төсләрне кабул итү. | Т.С.Комарова Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 50 бит | Октябрь<br>3 атна |
| 4 | Елгада көймә йөзә | Турыпочмакның почмакларын кисеп,формаларын үзгәртергә өйрәтү, композиция төзү күнекмәсен ныгыту. Кайчыны дөрес тотарга һәм аның белән эш итәргә күнектерү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 53 бит | 4 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Безнең шәһәрдә күп катлы өй төзелгән. | Кәгазь тасманы туры итеп кисәргә өйрәтү. Почмакларын тигезләү, рәсемне кисәкләрдән төзү. Аппликациядә олы йөрт образын тудыру. Пөхтә итеп ябыштыру күнекмәләрен ныгыту. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 57 бит | Ноябрь<br>3 атна |
| 6 | Гөмбәләр | Балаларны почмакларны түгәрәкләп кисәргә өйрәтү, кайчы белән дөрес эш итәргә өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной в детском саду деятельности. 58 бит | 4 атна |
| 7 | Чыршыга төймәләр | Түгәрәк һәм овал формаларны ясау өчен шакмак һәм туры почмакның почмакларын кисәргә өйрәтү, чиратлаштырып ябыштеру, пөхтә һәм чиста эш итү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 64 бит | Декабрь<br>3 атна |
| 8 | Кибеткә матур пирамидалар алып килделәр | Балаларны квадрат формасыннан түгәрәк кису кунекмәләрен беркетү. Пычак белән идарә итү алымнарын беркетергә. Төсләрне сайларга өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 65 бит | 4 атна |
| 9 | Уенчыклар төялгән арба | Кирәкле рәсем өлешләрен кисеп алырга күнектерү. Тасманы тигез өлешләргә бүлү. Шакмакларны түгәрәкләп кисү күнекмәсен ныгыту | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной в детском саду деятельности. 58 бит | Январь<br>3 атна |
| 10 | Очучы самолетлар. Әтигә бүләк | Балаларны рәсемне өлешләрдән җыеп һәр бер өлешнең үз урынын табып кую. Пөхтәлек тәрбияләү. Алган белемнәрен кулланып предметлар ясау, композиция төзү күнекмәсен ныгыту. Якыннарына игүтибарлы булыргаөйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 70 бит | Февраль<br>3 атна |
| 11 | Әнигә һәм әбигә матур чәчәк кисеп | Балаларга матур чәчәк һәм аның өлешләрен кисеп ябыштырырга ярдәм итү. Төсне тоемлау, күз | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной | 4 атна |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ябыштыру | алдына китереп эшләүне үстерү. Якыннарына игътибарлы булырга өйрәтү. | деятельности в детском саду. 71 бит | |
| 12 | Квадрат җирлеккә бизәк төшерү | Квадрат җирлеккә матур бизәк төшерергә өйрәтү. Геометрик фигураларны дөрес куеп кырыйга, уртага, почмакларга ябыштыру. Мөстәкыйльлелек тәрбияләү | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 72 бит | Март<br>3 атна |
| 13 | Кызыл түшләр һәм песнәкләр бездә кунакта. | Алган белемнәрен кулланып берничә кисәктән торган предметларның сурәтләрен пөхтә итеп ябыштырырга өйрәтү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 74 бит | 4 атна |
| 14 | Нәрсә түгәрәк, ә нәрсә овал була? | Шакмакны түгәрәкләп кисүне ныгыту, күзаллап ясарга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның иҗади мөстәкыйльлекләрен үстерү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 74 бит | Апрель<br>3 атна |
| 15 | Табышмаклар | Яссы геометрик фигураларны бер өлеше белән чагыштыра белү, әзер өлешләрдән рәсем ясау, вак детальләрне мөстәкыйль кисү. Җыйнак ябыштыруны күнектерү. Иҗатны, образлы карашны үстерү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 74 бит | 4 атна |
| 16 | Нәрсә телисең шуны кисеп ябыштыр | Балаларны алга таба эшләү ниятенә буйсындырырга өйрәтү. Турыпочмак, түгәрәк һәм вак детальләрен кисергә өйрәтү. Мөстәкыйльлек, иҗат тәрбияләү. | Т.С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 74 бит | Май<br>3 атна |
| 17 | Серле бакча | Балалар белән берлектә серле бакча тудыру, туры почмакларны тугәрәкләп кисәргә өйрәтү. | .С.Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. 74 бит | |

**Файдаланылган әдәбият**


2. Т.С. Комарова. Занятия по изобразительной деятельности в детском саду. М.: Просвещение, 1981.
3. Т.Г.Казакова. Занятия с дошкольниками по изобразительной деятельности. М.: Просвещение, 1995.

## Юл йөрү кагыйдәләре буенча аңлатма язуы

Балаларны юлларның машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган өлешләре (тротуар) белән таныштыру; светофорның кызыл, сары һәм яшел төсләренең мәгънәләрен аңларга ярдәм итү.

Җиңел һәм йөк машиналарының охшаш һәм аермалы якларын табарга, мөһим детальләрен (автомобильдә: кабина,руль, тәгәрмәчләр һ.б.), тору урынын (тәрәзә артында, биек, ерак) әйтә белергә өйрәтү. Хәрәкәт итү чараларының кайбер охшаш якларына игътибар итәргә күнектерү.

Балаларның дидактик материал белән булган мөстәкыйль уеннарына шартлар тудыру. Мөстәкыйль карау өчен төрле рәсемле китаплар, реклама буклетлары, техник уенчыклар тупланмасын карарга мөмкинлек бирү.

## Юл йөрү кагыйдәләре буенча перспектив план

| **Үткәрү вакыты** | **Дәресләр тематикасы** | **Дидактик уеннар** | **Хәрәкәтле уеннар** |
|---|---|---|---|
| сентябрь | “Йөк һәм җиңел машиналар белән танышу” | “Гараж”, “Ике бертөрле автомобильне эзләп тап” | “Төсле автомобильләр” |
| октябрь | “Урам белән танышу” | “Безнең урамыбыз” | “Миңа таба йөгерегез” |
| ноябрь | “Автобус” | “Автобусны ясап бетер”, “Дүртенчесе артык”. | “Чыпчыклар һәм автомобиль” |
| декабрь | “Йөк һәм маршрут буенча йөрүче транспорт чаралары” | “Кискәләнгән рәсемнәр”, “Кем нәрсәдә бара”. | “Поезд” |
| январь | “Төсләр иленә сәяхәт” | “Тиз җавап бир” | “Үз төсеңне эзләп тап” |
| февраль | “Шундый төрле машиналар” | “Кем нәрсәдә бара” | “Кошлар һәм автомобиль” |
| март | “Светофорны күзәтү” | “Светофор”, “Дөрес светофорны эзләп тап”. | “Светофорның төсләре” |
| апрель | “Транспорт төрләре һәм аларның аермалыклары” | “Кыен виражлар”, “Авомашинаны исеңдә калдыр”. | “Атлар” |
| май | “Йомгаклау: “Без барабыз, барабыз, барабыз” | “Аю баласына юлны аркылы чыгарга ярдәм ит”. | “Поезд” |

## Милли-төбәк компоненты.

Шәхескә белем бирү, аны тәрбияләү һәм тормышка әзерләүдә күп факторлар катнаша: гаилә, тирә-юнь, урам, табигать һәм шулар белән белән беррәттән милли-региональ үзенчәлекләр. Һәр халык, Һәр милләт үзенеңрухи байлыгын үзенчәлекле шартларда, үзенчәлекле юллар һәм алымнар белән туплаган. Аларның һәрберсе дөнья мәдәниятенә үзеннән сизелерлек өлеш кертә, баета. Милли рухи байлык аерым халыкның гына түгел, ул – гомумкешелек кыйммәтләренең нигезе. Димәк, балаларны кечкенәдән үк үз халкының , үз туган җиренең үзенчәлекләре белән таныштыру гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыруның башлангычы булып тора. Безнең бурыч – үткән буыннар туплаган рухи байлыкны саклап, баетып, аның кешелек тарафыннан иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү. Шуннан чыгып, программага милли-региональ компонент өстәлгән. Милли төбәк өлеше билгеле бер төбәкнең мәгариф өлкәсендә мәнфәгатьләрен, туган як мәдәниятен, гореф-гадәтләрне, тел һәм әдәбиятны, тарих, география һ.б. үзенчәлекләрне белү зарурлыгын билгели. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004) Татарстан халыкларын, аларның мәдәниятен һәм телләрен саклау, һәръяклап үстерүне, җәмгыятнең социаль-икътисади, рухи-әхлакый үсүендә һәр милләтнең иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм күркәм традицияләрен тулысынча файдалануны күздә тота. Тәрбия белем бирү программасында милли-төбәк компоненты кертелүе әлеге законны гамәлгә ашыруда зур ярдәмлек булып тора.

Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып уртанчылар төркемендә тәрбия һәм укыту бурычлары:

-Туган якның кошларына, хайваннарына, үсемлекләренә карата сакчыл һәм кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү.
- Балаларның сәламәтлекләрен ныгытырга дәвам итү.
- Өлкәннәрнең хезмәтенә кызыксыну тәрбияләү, хөрмәтләргә өйрәтү.
- Балаларның сөйләмнәрен үстерү.

**Милли-төбәк компонентларны исәпкә алып юнәлеш эчтәлеге**

Белем бирүдә төп бурычлар :

Туган төбәккә,балалар бакчасына хөрмәт тәрбияләү.Үзебез яшәгән шәһәребезнең күренекле урыннары белән таныштыру.

Татар халкының культура мирасына карата кызыксыну уяту.балаларны кул эшләре белән таныштыру .Борынгыдан калган мирасны сакларга өйрәтү.

| Милли –төбәк компонентының төп юнәлешләре эчтәлеге | | |
|---|---|---|
| 1. | Сәламәтлек | Татар халкының хәрәкәтле уеннары аша мөстәкыйль хәрәкәт эшчәнлеген тәрбияләү.Сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру (физминутлар,сулыш алу гимнастикасы,фонетик кунегүләр). |
| 2. | Физик культура | Татар һәм рус халкының уеннары белән таныштыру һәм кызыксыну уяту. Балаларның иҗат итү сәләтен үстерү (төрле уен вариантлары уйлап табу). Физик хәрәкәтне үстерү: хәрәкәтле уен вакытында, тизлекне, осталыкны,түземлелекне үстерү, камилләштерү, кунектерү. |
| 3. | Социальләштерү | РТ һәм РФ турында беренчел белемнәрне формалаштыру. Өлкәннәргә һәм яшьтәләренә карата ягымлы булу. Үз-үзеңне тоту сыйфатларын тәрбияләү. Дөреслек, дуслык, яхшылык, батырлык турында белемнәрне үстерү, тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Хезмәт | Үз-үзенә мөстәкыйльлек  һәм затлы рәвештә хезмәт күрсәтү (өлкәннәр ярдәменнән башка киенү, чишенү, киемнәрне төрү, әлү). Төркемне, мәйданчыкны  өлкәннәр ярдәме белән чиста һәм тәртиптә тоту. Мөстәкыйльрәвештә гөлләрне тәрбияләү (су сибү, төпләрен йомшарту, тузанын (яфрак) сөртеп алу). Хезмәтнең төрлелеге файдасы  турында уз төбәк шагыйрьләренең шигырьләр,  хикәяләр аша күзаллауларны үстерү. Хезмәткә катнашу, мөстәкыйль хезмәт курсәтү теләге булдыру, үстерү. Гади генә эшләрне кушкан йомышларны мөстәкыйль рәвештә башкарырга күнектерү. |
| 5. | Куркынычсызлык | Бөҗәкләр, хайваннар белән тормышта була торган куркыныч чыганаклар турында күзаллаулар булдыру. Юлның машина һәм җәяүле йөри торган өлеше белән таныштыру. Юлда йөрү кагыйдәләрен ныгыту. |
| 6. | Матур әдәбият белән таныштыру | Татар һәм рус фольклорының үрнәкләре белән таныштыру. Әдәби әсәрләрнең мәгънәсенә дөрес төшендерү. Әкиятләр, шигырьләр тыңлый белү осталыкларын булдыру, татар фольклорының гүзәл үрнәкләре белән таныштыру. |
| 7. | Танып белү | Туган төбәкнең куренекле урыннары,  үсемлекләр, хайваннар дөньясы белән таныштыру.Татар халкының культура мирасына карата кызыксыну уяту. |
| 8. | Музыка | Татар халкының музыкаль инструменты –гармун белән таныштыру. Көйнең характерын сиземләүне үстерү, татар биюенең гади хәрәкәтләре белән таныштыру. |
| 9. | Иҗади сәнгать | Татар халкының декоратив –гамәли сәнгатенә кызыксыну формалаштыру.  Городец уенчыклары, бизәкләре белән таныштыру. Татар орнаменты белән әйберләрне бизәргә өйрәтү, иҗади сәнгать эшчәнлегендә “Яфрак”, “Ләлә”, “Кыңгырау” бизәкләрен куллану. |
| 10. | Коммуникация | Ике телдә дә өлкәннәр белән иркенләп аралашу. Сөйләмнең бөтен компанентларын үстерү. Яңа технологияләр, уеннар аша балаларда аралашу теләге уяту. |

**Уртанчылар төркемендә ата-аналар белән эш планы**

| Ай исеме | Үткәрү вакыты | Эш төре |
|---|---|---|
| Сентябрь | 1нче атна | Ата-аналар почмагын тәртипкә китерү, җыелышка кирәкле мәгълүматны әзерләү |
| | 1нче атна | “Без инде уртанчылар” темасына ата-аналар җыелышы үткәрү |
| | 1нче атна | Уку елына кирәк булган уку әсбапларын алу |
| | 1-2нче атна | “Гомуми тәкъдимнәр”, “Тышкы кыяфәткә таләпләр” темаларына һәр ата-анага кушымталар өләшү |
| | Ай дәвамында | “Ни өчен бала бакчага барырга теләми”, “Өйдә балаларның үз-үзләрен карау күнекмәләрен тәрбияләү”, “Гаиләдә мактау һәм шелтәләү”, “Баланың көйсезләнүенә ничек карарга” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3нче атна | “Баланы ничек мөстәкыйль киенергә өйрәтергә”, “Шәхси гигиена күнекмәләре һәм аларның бала үсешендәге урыны” темаларына консультация |
| Октябрь | 1нче атна | “Тел һәм аның йорты белән танышу” – балаларга артикуляцон гимнастика – папка әзерләү |
| | 1нче атна | Бакча өчен үз вакытында түләү кагыйдәләре турында һәр ата-ана белән әңгәмә |
| | 2нче атна | Консультация “Гафу итәргә өйрәнәбез” |
| | Ай дәвамында | “Балаларга нәрсә укырга”, “Дөрес итеп сөйләшергә һәм суларга өйрәнәбез” темаларына консультация |
| | 4нче атна | Ата-аналар комитеты белән “Көз бәйрәмен” үткәрү турында сөйләшү |
| | 4нче атна | “Көз бәйрәмен” үткәрү |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| Ноябрь | Ай дәвамында | “Балаларны халык аваз иҗатына нигезләнеп тәрбияләү”, “Кул моторикасын үстерү” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 2нче атна | “Бармак уеннары ярдәмендә телне шомартабыз” практик киңәшләр |
| | 2нче атна | Консультация “Дөрес суларга өйрәнәбез” |
| | 3нче атна | “Бала сөйләшергә өйрәнә” кечкенә төркемнәр белән тематик әңгәмә |
| | 3нче атна | Чыныктыру чараларын үткәрү һәм алар өчен кирәкле булган материалны булдыруда комитет белән эш |
| | 4нче атна | Саф һавада ата-аналар белән берлектә спорт бәйрәме үткәрү |
| Д е к а б р ь | 1нче атна | “Тиздән кышкы бәйрәмнәр” – күчмә-папка ясау |
| | 2нче атна | “Дөрес сөйләшик” темасына ата-аналар җыелышы. Планы:<br>1. Балалар өчен артикуляцион гимнастика.<br>2. “Балаларны халык аваз иҗатына нигезләнеп тәрбияләү”.<br>3. Ата-аналарга киңәшләр, тәҗрибә уртаклашу. |
| | Ай дәвамында | “Бала тыңламаса нишләргә”, “Баланың үз-үзенә йомылуы” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 1-2нче атна | Баланы бакчага вакытында алып килү, бакча һәм түләүле түгәрәкләр өчен һәр айның 10 сыннан калмый түләргә икәнлеге турында һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3нче атна | “Кышкы уеннар”, “Кышкы бәйрәмнәрне каршылыйбыз”- кечкенә төркемнәр белән тематик әңгәмә |
| | 3нче атна | Комитет белән бәйрәмне үткәүгә әзерлек турында сөйләшү. |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | 4нче атна | “Бала белән дөрес сөйләшү”, “Баланың тормышын һәм сәламәтлеген саклау” кушымталар өләшү |
| | 4нче атна | Кыш бәйрәмен үткәрү |
| **Январь** | 2-3нче атна | “Телевидение һәм кечкенә балалар психикасы”, “Баланың куркуы” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 2-3нче атна | Комитет белән дидактик, өстәл уеннары, рәсем дәфтәрләре алу турында сөйләшү |
| | Ай дәвамында | “4-5 яшьлек балаларның үсеш үзенчәлекләре”, “Үзсүзлелек һәм киреләнү” темаларына консультация |
| | 2нче атна | Мәйданчыкта кардан корылмалар төзү |
| | 3нче атна | “Бала үсешенә ата-аналар куйган таләпләрнең тәэсире” күчмә-папка төзү |
| | 4нче атна | “Әти, әни һәм мин – без тату гаилә” – рәсемнәр конкурсы |
| **Ф е в р а л ь** | Ай дәвамында | “Гафу итәргә өйрәнәбез”, “Гаиләдә кем баш, яки тәрбиядәге ялгышлар” темаларына һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3нче атна | Баланы бакчага вакытында алып килү, бакча һәм түләүле түгәрәкләр өчен һәр айның 10сыннан калмый түләргә икәнлеге турында һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3-4нче атна | “Ата-ана булу осталыгы” кечкенә төркемнәр белән тематик әңгәмә |
| | 3нче атна | “Китап - иң яхшы дус һәм ярдәмче” темасына консультация |
| | 4нче атна | “Яссытабанлыкны булдырмау чаралары”, “Игътибар, урам!” кушымталар әзерләү |
| | 4нче атна | Әтиләребезгә бүләк әзерләү |

| | | |
|---|---|---|
| **М а р т** | 1нче атна | Комитет белән Әниләр бәйрәменә әзерлекне сөйләшү |
| | 1нче атна | “Әниләр һәм әбиләр бәйрәме” үткәрү |
| | 1-2нче атна | “ОРЗны булдырмау чаралары”, “Файдалы үләннәр” кушымталар әзерләү |
| | Ай дәвамында | “Балаларга телевизор карауда булган таләпләр” һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 1-2нче атна | Баланы бакчага вакытында алып килү, бакча һәм түләүле түгәрәкләр өчен һәр айның 10сыннан калмый түләргә икәнлеге турында һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 3нче атна | “Балаларга сәламәтлекләрен ныгытырга ярдәм итегез” темасына консультация |
| | 3нче атна | “Телевизион бәйлелек” тест үткәрү |
| | 4нче атна | “Сәламәтлек – зур байлык” темасына ата-аналар җыелышы. Планы:<br>1. “Балаларга сәламәтлекләрен ныгытырга ярдәм итегез”<br>2. Балалар өчен зыянлы ашамлыклар.<br>3. Ата-аналарга киңәшләр, тәҗрибә уртаклашу. |
| **А п р е л ь** | 1нче атна | Космоска багышланган рәсемнәр күргәзмәсе |
| | 1нче атна | “Эш арасында уеннар” кушымталар әзерләү |
| | Ай дәвамында | “Рәсем ясауның традицион булмаган ысуллары” һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 1-3нче атна | “Баланы шәхес итеп үстерүдә сюжетлы – рольле уеннарның файдасы” темасына консультация |
| | 4нче атна | “Бала тормышында уен һәм уенчыклар” анкета - сорау алу |
| **М** | 1нче атна | Җиңү бәйрәме үткәрү |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | Ай дәвамында | “Уен формасында чыныктыру”, “Бала үсешендә хәрәкәтле уеннарның роле” темаларына консультация |
| | 2-3нче атна | “Бала уенда нәрсәгә өйрәнә”, “Балага нинди уенчыклар кирәк”, “Таныш булмаган кешеләр белән аралашу күнекмәләре” кушымталар әзерләү |
| | 3-4нче атна | “Бергәләп уенчык ясыйбыз” һәр ата-ана белән индивидуаль әңгәмә |
| | 4нче атна | “Әйдәгез бергәләп уйныйбыз” темасына ата-аналар җыелышы. Планы:<br>1. “Безнең балачак уеннары” чыгыш.<br>2. “Бала тормышында уен һәм уенчыклар” анкета - сорау алу нәтиҗәләре.<br>3. Еллык эшкә нәтиҗә ясау һәм җәйге чорның планын кабул итү.<br>4. Группага ремонт ясау турында сөйләшү.<br>5. “Күңелле балачак!” бәйрәменә әзерләнү. |

**Мониторинг**

Балаларның планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү буенча мониторинг системасы арадаш нәтиҗәләрне һәм программаны үзләштерүнең йомгаклау нәтиҗәләрен бәяләүне күздә тота.

**Белем бирү процессы мониторингы**

Үткәрү вакыты___________________________________

| Баланың исеме | Белем бирү өлкәләре | | | | | | | | | | | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Физик үсеш | | Социаль-шәхси үсеш | | Танып белү-сөйләм үсеше | | | Сөйләм үсеше | | Нәфис-нәфасәти үсеш | | |
| | Сәламәтлек | Физиккультура | Социальләштерү | Хезмәт | Танып белү | ФЭМП | Төзү | Матур әдәбият | Аралашу | Иҗади сәнгать | Музыка | |
| | | | | | | | | | | | | |

Бәяләү критерийлары:

1 балл – күп компонентлар үзләштерелмәгән;

2 балл – кайбер компонентлар үзләштерелмәгән;

3 балл – югары балл, яшенә туры килә;